РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Нижнекамский муниципальный район
СОВЕТ
муниципального образования
«пгт Камские Поляны»

423564, «пгт Камские Поляны», д.4/04,
тел: (8555) 35-00-01, факс: 35-00-04

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
«Кама Аланы штп»
муниципальберәмлеге
СОВЕТЫ

423564, «Кама Аланы штп», 4/04йорт,
тел: (8555) 35-00-01, факс: 35-00-04

# Карар

2019 елның 1 октябреннән № 21

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында»

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 6 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең 2018 елның 10 апрелендәге генераль планы проекты буенча җәмәгать тыңлавы нәтиҗәләрен, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кама Аланы штп» муниципаль берәмлеге генераль планы проектының каршылыкларны җайга салу буенча килештерү комиссиясенең 2009 елның 12 сентябрендәге 45 номерлы беркетмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кама Аланы штп» муниципаль берәмлеге Советы карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең генераль планын расларга (теркәлә).

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының 2010 елның 27 маендагы 19 номерлы «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогын планлаштыру проектыһәм генераль планы турында» карарында:

2.1. исемендә «һәм генераль планы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2.1 пунктта «һәм генераль планы» сүзләрен төшереп калдырырга;

карарга кушымтада:

2.3.«Кама Аланы штп планлаштыру проекты һәм генераль планы» бүлегенең атамасында һәм тексты буенча «генераль планы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.4. «Кама Аланы штп генераль планының максатлары, бурычлары» һәм «генераль план составы» бүлекләрен үз көчләрен югалткан дип танырга;

2.5. «Килештерү һәм җәмәгать тыңлавы» бүлегендә»:

бүлек атамасында «килештерү һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

3. «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башкарма комитетына әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында http://kampol.e-nk.ru урнаштыруны йөкләргә.

4. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм архитектура идарәсенә расланган документны Россия Федерациясе территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасының (РФ ТП ФДМС) рәсми сайтында урнаштырырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны ТР Түбән Кама муниципаль районының «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р.Сәлахетдиновка йөкләргә.

«Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.А. Павлов